**“Башкортостан Республикасы Агыйдел шәһәре шәһәр округы Үзәк китапханәсе” муниципаль автоном мәдәният учреждениесе**

**Хезмәтләндерү бүлеге**

# *Басып сайрар талы бар*

## *Мәдинә Маликовага 85 яшь тулу уңаеннан*



**Укырга тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге**

**Агыйдел - 2020 ел**

*Төзүче : Ә. Х. Әюпова*

*Басып сайрар талы бар : Мәдинә Маликовага 85 яшь тулу уңаеннан : укырга тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге / төз. Ә. Х. Әюпова. – Агыйдел : “БР Агыйдел шәһәре ШО  Үзәк китапханәсе” МАМУ, 2020*

## Төзүчедән

Күренекле татар язучысы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре,Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (*2017*)Мәдинә Маликовага 85яшь тулу уңаенан Үзәк китапхана “Басып сайрар талы бар” дигән укырга тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге әзерләде. Исемлек Мәдинә Маликованың үз әсәрләре, тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыра.Библиографик кулланма киң катлам укучыларга тәгаенләнгән.

Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстан АССРның Сарман районы Мортыш Тамагы авылында колхозчы гаиләсендә туган. Үз авылларындагы җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1949—1959 елларда башта Минзәлә педагогия училищесында, аннары Казан дәүләт педагогия институтында укый. Институтның тарих-филология факультетын уңышлы тәмамлап чыкканнан бирле ул берөзлексез журналистлык хезмәтендә: 1959—1964 елларда “Чаян” журналында корректор, ә 1964 елдан башлап “Азат хатын” журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли.

1978 елдан ул “Азат хатын” журналының җаваплы секретаре вазифаларын башкара. Ул— 1970 елдан КПСС әгъзасы…
Мәдинә Маликова 1993 елдан Бөтентатар “Кызыл Хач” җәмгыяте президенты да.

Мәдинә Маликованың әдәби иҗат юлындагы беренче адымнары да журналистлык язмаларыннан — көндәлек матбугат өчен хәбәрләр, документаль очерклар, репортажлар, мәкаләләр язудан башлана. Журналист буларак, ул күп йөри, төрле профессия кешеләре белән очраша, тормыш материалын тырышып өйрәнә. Аны бигрәк тә яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр, гаилә һәм тәрбия проблемалары, кешенең җәмгыятьтәге урыны, бурычы, хезмәткә карашы мәсьәләләре кызыксындыра. Бу темалар, күп санлы очеркларында, мәкаләләрендә конкрет яктыртылудан тыш, язучының әдәби әсәрләре — хикәя һәм повестьларының да төп эчтәлеген һәм идея юнәлешен тәшкил итә.
Гомумән, язучы, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, кешедәге рухи дөньяның серләрен, нечкәлекләрен ачарга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгын анализлап, яшәешнең төп мәгънәсе һәм максаты үз идеалыңа,

димәк, җәмгыятькә дә хезмәт итү икәнлеген расларга омтыла…
М. Маликова детектив жанрында да уңышлы гына эшли,лирик хикәяләр авторы буларак та укучыларга таныш…

М. Маликова 1974 елдан бирле Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены һәм, идарә каршындагы Матур әдәбият тарату комиссиясе җитәкчесе буларак, актив җәмәгать эше алып бара.

Матбугат һәм әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1976 елда Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелә, ә очерклары һәм мәкаләләре өчен 1980 елда Татарстан АССРның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе белән бүләкләнә...

Давыллы еллар, сикәлтәле юллар, иҗат газаплары, ниһаять, тормыш, көнкүреш мәшәкатьләре күпме генә иңенә басмасын, мәшһүр язучыбыз Мәдинә Маликова әле бүген дә, яшь чагындагыдай, күркәм һәм сөйкемле. Энергиясенә дә сокланырлык.

Татар әдәбияты бай һәм үзенчәлекле, һәр язучының үз аһәңе, үз стиле, язу манерасы,  китаплары бар. Алар


арасында Мәдинә Маликова әсәрләре аерым урын-ниша алып торалар.

Мәдинә Маликова иҗатына колачлылык, масштаблылык, киң планлылык хас .
Мәдинә Маликова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Күренекле әдибебез киләчәктә дә яңадан-яңа әсәрләре белән укучыларны куандырыр, дип, чын күңелдән ышанасы килә. Иң әһәмиятлесе шул: мөхтәрәм язучыбызның басып сайрар талы бар. Ул — аны яраткан, хөрмәт иткән халкыбыз. Язучы Мәдинә Маликова иҗатының төп хасияте турында уйланганда да әсәрләрендәге зыялылыкка игътибар итәсең.

Бүгенге укучы яхшы хәзерлекле, ул әдәби әсәрләрдә тормыштагы төрле хәл-әхвәлләрне күрсәтү белән генә канәгать түгел. Син аңа яшәешнең хикмәтләрен ач, кешенең теге яки бу адымын ясауга китергән сәбәпләрнең тирән фәлсәфәсен шәрехлә, гамәлләренең ахыр нәтиҗәләрен гомумиләштерүләр ярдәмендә күңелгә үткәрерлек итеп яса. Ягъни укучы белән фикердәш бул, аны борчыган сорауларны ачыкларга тырыш, һич югы шул мәсьәләләрне укучы уйланырлык итеп куя бел. Мәдинә Маликова шушы таләпләрнең барсына да җавап бирә.

Гаффарова Э.

**Көмеш билбау : детектив әсәрләр (роман, повестьлар). - Казан : Ихлас, 2013. – 432 б.**




*Авторның детектив сюжетка корылган романында узган гасырның туксанынчы елларында – үзгәрешләр чорында булган вакыйгалар. Яшьләрнең мәхәббәте, шәхес буларак житлегүе, кискен бәрелешләре тасвирлана. Китапка язучының элегрәк язылган детектив әсәрләре дә кергән.*

.




**Мендем биек тауларга : повестьлар, роман. –Казан : Ихлас, 2015. – 400 б.**

*Бу китапка кергән ике повесть һәм бер романда гасырлар алышынган чор, үзгәреш елларында булган вакыйгалар тасвирлана. Ил әкренләп хәлсезләнде, аннары бөтенләй таралды. Күпләр зур сынаулар аша үтәргә мәҗбүр булды.*

**Красный цветок : роман, рассказы / [пер. с тат. М. Г. Маликовой, Р. А. Фаткуллиной, М. Г. Сафиной, Р. Г. Ахунова; вступ. сл. Л. Хисматовой ] – Казань : Тат. кн. Изд-во, 2015. – 351 б.**




*Роман о судьбе двух поколении: родителей, жизнь которых пришлась на годы тоталитарного режима, идетей, повзрослевших ко времени рапада СССР. В романе расскрываются сложные отношения между поколениями и любовь, освещающая жизнь и согревающая сердца.В книгувключены также избранные рассказы, написанные в разные годы.*




**Югалган якутлар: повестьлар, пьесалар. – Казан : Рухият, 2004. – 400 б.**

*Бу китап сөю турында, сөйгәненә илтә торган юллар турында. Илләр-кыйтгалар арасын очкычларда очып кына узып булган бу заманда нигә шулай сикәлтәле икән йөрәкләрдән-йөрәкләргә илтә торган сукмаклар? Алардан бәргәләнеп-кыйналып барганда,*

*башкаларның да язмышын имгәтмибезме без?*
*Бу әсәрләрдә тасвирланган заман кешеләренең кичерелешләре шул турыда уйландыра*

**Кызыл гөл: романнар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2005. – 414 б.**




*Сөйгән ярын назга күмеп, бәхет бишегендә генә тибрәтү турында кем генә хыялланмый икән? Әмма бу матур хыялга ирешү юллары сикәлтәле, кантарлы. Аларга бер яктан без үзебез ясаган хаталар киртә салса, икенче яктан ил өстенә килгән фаҗигаләр, иҗтимагый яшәешнең көйсезлекләре ташлар өйгәндәй итә. Изге хыялларың чынга ашсын дисәң, үзеңне генә түгел, илеңне кайгыртып яшәргә кирәк*





**Юкә чәчәк аткан чак иде : романнар. – 2-е изд. – Казан : Сүз, 2017. – 480 б.**

*Адәм баласын кеше иткән төп сыйфат – ул матурлыкны күрә белү, аннан тәм таба белү, аны үз кулларың белән булдырып, тормышны бизәү.*


*Бу китапка кергән әсәрләр матурлыкны тудыручы чордашларыбыз – рәссәмнар, артистлар турында, аларның рухи кыйбласы, ижади язмышы, мәхәббәте туры*

**Өермә: роман, повестьлар. – Казан: Идел-Пресс, 2003. – 352 б.**




*Ник яшибез без бу дөнъяда? Кемне сөябез? Нәрсә өчен? Хисләргә бирелгәндә әхлак кануннарын онытмыйбызмы?Әгәр онытып җибәрсәк, безне моның өчен нинди җәза көтә?Бу әсәрләрдә тасвирланган заман кешеләре менә шушы сорауларга җавап эзлиләр. Ашкыналар, абыналар, ялгышалар, егылалар, әммә күңелләре белән саф булып калалар.*

*"Өермә" романының башында: "...әсәрдә тасвирланган һәммә вакыйгалар һәм образлар баштанаяк уйлап чыгарылган", дип куелган булса да, без аның автобиографик рухта язылганын беләбез. Анда хәйрия җәмгыятенең төзелү тарихы, эшендәге авырлыклар һәм куанычлар бик тәфсилләп сүрәтләнә".*




**Сандугачның күз яше : роман, повесть, хикәяләр. – Казан : Ихлас, 2018. - 400 б.**

*Бугенге көндә яшь кешегә үз юлын сайлау өчен зур мөмкинлекләр бирелгән. Шул ук вакытта төрле яктан куркыныч, афәт яный. Аларга юлыкмау, юлыксаң бирешмәү өчен ныклы таяныч кирәк. Андый таяныч – мәхәббәт. Бу романда яшьләрнең катлаулы язмышы тасвирлана.*

*Хисмәтова Л. Әсәрләрендә буыннар язмышы: Мәдинә Маликовага 80 яшь //Казан утлары. – 2015 - №9. – Б. 171-177*







***Безнең адрес:***

***452920, Агыйдел шәһәре,***

***Беренче төзүчеләр ур., 7 А***

***Тел.: 8(34731) 27-3-56***

***E-mail: mukcbs55@mail.ru***

***Сайт:http://agidelbibl.ru /ү***

***В Контакте:***

***Центральная-Библиотека***

***Город-Агидель***

***Без эшлибез:***

***Үзәк китапханә***

***Эш сәгате: 10.00 – 19.00***

***Төшке аш: 13.00 – 14.00***

***Ял көне : шимбә***

***Агыйдел шәһәре тарихи-туган якны өйрәну музее***

***Эш сәгәте: 10.00 – 19.00***

***Төшке аш:13.00 – 19.00***

***Ял көне: шимбә***

***Балалар моделле китапханәсе***

***Эш сәгәте: 10.00 – 19.00***

***Төшке аш:13.00 – 19.00***

***Ял көне: шимбә***